**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2022 Балык Бистәсе штп. № 330пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 30.09.2021 №218пи карары белән расланган мәгълүмати элмә такталарын урнаштыру, элмә такталарны урнаштыру дизайн - проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 15.08.2022 ел, №1415 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының 1 пунктындагы а пунктчасы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 30.09.2021 №218пи карары белән расланган мәгълүмати элмә такталарын урнаштыру, элмә такталарны урнаштыру дизайн - проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба-Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Формалаштырылган гарызнамәне формат-логик тикшерү, мөрәҗәгать итүче электрон формадагы һәр юлны тутыру процессында орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, Бердәм портал тарафыннан автоматик рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон формасында дөрес тутырылмаган юл ачыкланганда мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында электрон формада мәгълүмати хәбәр җибәрелә.”.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д. Н. Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р. Л. Исланов